# Әдәби әсәрдә халык җырлары һәм бәетләр

Җамалиева Л.Ф, ф.ф.к.,

КФУ ИФИ доценты

Күренекле язучы Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” автобиографик повесте халык авыз иҗатының әдәби энциклопедиясе булып саналырлык әсәр. Татар халкының XX йөз башында уздырылган йолалары, сөйләнгән әкиятләре, риваять-легендалары әлеге әсәрдә кечкенә Гумәр исеменнән бик матур тасвир ителә.

Повестның кереш өлешендә Г.Бәширов аны иҗат иткәндә максатчан рәвештә фольклорга мөрәҗәгать итүе хакында яза: “Бу әсәр, нигездә, бер авыл тормышыннан алып язылган. Яңасала зур авыл түгел. Шулай да ул Казан ханлыгы заманыннан бирле үк яшәп килгән бик борынгы авылларның берсе булганлыктан, җирендә-суында, тормыш-көнкүрешендә, риваятьләрендә халкыбыз тарихыннан хәтсез күп кадерле эзләр саклый алган. Ул эзләрдә халкыбызның асыл сыйфатлары чагыла. Алар тапкыр һәм зирәк сүз булып, үзәк өзгеч җыр моңы яки дәртле бию көе булып, гүзәллеккә сокланучы үткен күз нуры яисә игелекле гореф-гадәтләр, тырышлык һәм эшчәнлек рәвешендә әледән-әле балкып чыгалар.

Бу кыйммәтле рухи хәзинәбезнең бер өлешен генә булса да әсәремә теркәп калуым белән мин үземне бәхетле саныйм” .

Г.Бәширов, татар әдәбиятының күренекле язучысы гына түгел, ул халык авыз иҗатын җыю, бастырып чыгаруга да үзеннән бик зур өлеш керткән әдип. Узган гасырның 50-60нчы елларында аның тарафыннан һәм күренекле фольклорчы Х.Ярми белән берлектә күпсанлы әкият җыентыклары төзеп бастырыла. “Туксан тугыз мәзәк”, “Миң дә бер мәзәк” җыентыклары да язучының күпьеллык эшчәнлеге нәтиҗәсе. Шул рәвешчә, халык иҗатын мөкиббән булган авторның әдәби иҗатында да халык традицияләренә еш мөрәҗәгать итүе бик урынлы.

“Туган ягым - яшел бишек” әсәреннән фольклорның барлык жанрларының әдәби кулланылышына мисаллар китерергә мөмкин. Без бу

мәкаләдә әлеге әдәби әсәр текстында халык җырлары һәм бәетләрнең кулланылышын өйрәнүне максат итеп куйдык. Фольклорчылар тарафыннан татар халык җырларын филологик төркемләү мәсьәләсендә төрле карашлар яшәп килсә дә, соңгы елларда бу юнәлештә эшләүче галимнәр җырларны йола җырлары, уен-бию җырлары, тарихи һәм лирик җырлар дигән төркемнәргә бүлеп өйрәнергә тәкъдим итәләр [Миңнуллин, 2003 : 44].

Теләсә кайсы әсәрдә, шул исәптән, безнең тикшергән текстларда да халык җырларын табарга мөмкин. Г.Тукай сүзләре белән әйткәндә "халыкның халәте рухиясен билгеләүче" җырлар кеше күңеленә бик якын. Әсәрдә халык җырларының барлык төрләре дә очрый. Йола җырларына мисалга, Өммикамалның никах туенда башкарылган кода җырларын әйтә алабыз. Бу җырларда туйда кодаларга булган хөрмәтне, олылауны күрергә мөмкин:

Ничекләр генә килдегез, ай, сез безгәй,
Батмыенча гына лай диңгезгәй.
Газиз кодалар бит, ай, сез безгәй.
Нинди сыйлар гына куйыйк соң сезгәй...
Таң иртәләр генәй тышка чыксам,
Йолдызкайлар сөйләшәй ай белән;
Әйтер сүзләребез хәттин ашкан, Бәшир кода,
Әйтербез ләй әли җай белән... [Бәширов, 1990: 243].

Кызганычка каршы, соңгы елларда туй мәҗлесләрендә кодаларның кара-каршы җырлашулары, макташулары бөтенләй бетеп бара диярлек. Студентларның фольклор практикасы сораулыкларында бу юнәлештәге сорауларга җавап табучылар бик сирәк. Туйны алып баруны тамадаларга йөкләп, халык табигый рәвештә җырлашып утыруны бөтенләй онытып бара. Киләчәктә әдәби әсәрне йолаларның аерым чорда ни рәвешле башкарылуы турында мәгълүмат алу өчен бердәнбер чыганак итеп карау куркынычы да бар.

Яшьләрнең шат-шаян уен-бию җырлары әсәрдә аулак өй күренеше аша бирелә. Бик борынгы җырларның берсе "Хан кызы, ач ишегең..." нәкъ менә

аулак өйдә башкарылган. Кызлар егетләрне бик ялындырып, җырлатып кына өйгә кертәләр:

Егет:

Хан кызы, ач ишегең, мин керием,
Синең йөзең нурлы диләр, мин күрием!
Кыз:
Минем йөзем күреп сиңа нидер файда,
Кичләрдәге тулган айны күрмисеңме?

Күрәбез, җыр монда тулы вариантта түгел. Әлбәттә инде XX йөз башында, бигрәк тә гап-гади татар авылында хан кызлары юк. Егетләр, махсус, кызларны хан кызына тиңләп мактап, шул җырны ишек ачтыру чарасы итеп кулланалар.

Тарихи җырлар көндәлек тормышта еш яңгырамыйлар. Әсәр текстында да без аларны күп очраттык дип әйтә алмыйбыз. Бары тик, сугыш башлангач, хәрби хезмәткә алынучылар тарафыннан башкарылган җырлар буларак кына мисалга китерергә мөмкин.

Әдәби әсәрләрдә аеруча киң кулланылучы җырлар лирик җырлар төркеменә карый. Бу җырлар, чыннан да, кешенең рухи халәтен чагылдыру өчен бик уңышлы. Аларда геройның хәсрәте дә, шатлыгы да чагылыш таба. Лирик җырлар, әлеге повестьта сурәтләнгән герой − ятимлек ачысын тоеп үсүче Әхмәт тарафыннан бик еш башкарыла:

Иртә генә торам, кырларга чыгам,
Ак куяннар эзли, - тал тапмый,
Өйләргә дә керәм, тышка чыгам,
Ятим башкайларым ямь тапмый.

Әхмәтнең эшкә барганда я кайтканда, “Бу дөньяларның эчләрендә миннән моңлыраклар бар микән?” дип җан ачысы белән тормыш авырлыгы, ялгызлык хәсрәте, ятимлек ачысы турындагы җырларын тыңлап, авыл халкы елый.

Лирик җырларның башка тематик төркемчәләренә дә мисаллар бик күп. Батрак егет Әхәтнең сөйгән яры Өммикамалны башка егеткә кияүгә биргәч, ул “кимсетәләр мал юкка” дип җырлый.

Җырларга бик якын торучы лиро-эпик жанрга караган бәетләр дә әсәр тукымасына аерым вакыйгаларга бәйле рәвештә бик уңышлы кертелгән. Дини каршылыклар турында бер фаҗигале мәхәббәт тарихы бар. Татар егете Гайнулла белән күрше авылдан керәшен кызы Анный мәхәббәте бик үкенечле тәмамлана. Алар аерылырга теләмәгәч, Себергә озатылалар. [Бәширов, 1990: 221]. Монда бәет тексты юк, әмма бу бәет сюжеты икәнлеген чамаларга мөмкин. Язучы Гайнулла белән Анныйның саубуллашу җырын бирә:

Нарат башкайлары киртләч-киртләч,
Асыл кошлар кунар ояга;
Безне җибәрдек дип масаймагыз,
Бездән усалраклар туар дөньяга. [Бәширов, 1990: 221]. Җыр

буларак тәкъдим ителсә дә, бу бәет текстлары белән бик аваздаш.

Бәет буларак язылмаса да, бәет сюжеты Мазлуманың җизнәсе тарафыннан коллыкка сатылуы турында сөйләгәндә дә күренә. Әмма Мазлума, бер шәфкатьле хатын ярдәмендә бу коллыктан котылу бәхетенә ирешә, соңыннан үз башыннан кичергәннәрне дусларына сөйләгәндә әлеге җырны башкара:

Персиян мылтык корадыр ак куяннар атарга,
И әткәем, оят кирәк газиз кызыңны сатарга.
Хайван саткан барышниктай күп кыз җыйган башыгыз,
Кемгә генә төшәр икән безләрнең күз яшебез? [Бәширов, 1990: 287].

Хикәяләүче сүзләреннән, Гүмәрләр гаиләсендә кичләрен җыелып китап уку традициясе булуы аңлашыла. “Андый кичләрне мәдрәсәдә булсын, аерым өйләрдә булсын, Сак-Сок бәетеннән дә күп укылган китап булдымы икән? Аны тыңларга күрше хатыннары да, яшь-җилбәзәк тә керә торган иде.

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,

Сак белән Сокның бәетен ишетәсе...-

дип башлап җибәрүенә, өйдә чебен очканны ишетерлек тынлык урнаша. Балаларын сагынып көне-төне күз яше түгүче бичара ана белән ата, биек тауның ике ягында берсе Сак дип, икенчесе Сок дип моңаючы кошлар сурәтенә кергән ике бәхетсез бала күз алдына килә. [Бәширов, 1990: 299].

Повестьта сурәтләнгән сәяси вакыйгаларның , 1914 елгы сугышның да шәхси фаҗигаләр турындагы бәетләр күпләп туруга сәбәп булуы аңлашыла. Авыл белән фронт арасында аралашу хатлар аша бара. Нәбиулладан килгән хатта солдат бәете язылган:

Күрмидер синең күзең,
Каплый мылтык төтене;
Туп ярылгач яннарыңда
Калмый кеше бөтене.
Кайсысының кулы юк,
Кайсы ята аяксыз;
Монда кеше меңләп кырыла,
Үлем безгә аяусыз. [Бәширов, 1990: 348].

Биредә шәхси фаҗигаләр, мифологик эчтәлектәге “Сак-Сок” бәете турында сүз булды. Әсәрдә бүгенге көндә бик сирәк очрый торган сатирик бәеткә дә мисал бар:

Әхмәтҗанның атлары;
Улак төбен кимерә;
Әхмәтҗанның кызлары
Хур булдык дип тилмерә
Чәң-чәң өргән Сарбаеңны
Типкәләмә, Әхмәтҗан;
Без чыгарган бәет түгел,
Үпкәләмә, Әхмәтҗан.

Әлеге мисал халыкның авылда булган бер генә вакыйгага карата да битараф булмавы турында сөйли. Еш кына кемгәдер әйтеләсе сүзләр дә турыдан-туры түгел, фольклор әсәрләре аша әйтелә. Бу халыкның җырга-сүзгә сәләте, дөньяны шигъри күзаллавы турында сөйли.

Әсәр текстында фольклор берәмлекләрен куллану белән бергә авторның халык иҗатының яшәү шартларына да игътибар итүе җбик кызыклы. Дөрес бу махсус рзвештә эшләнми, сүз барышында бик табигый яңгырый. Әйтик, сабан туен сурәтләгән бүлектә Гумәрнең әнисе Зифа белән күрше Гыйльми түтәй сөйләшкәндә Зифа баянчыны танымавын әйтә. Гыйльми түтәй: “Кем булсын, Әзәк илләре ич! Минем якташлар. Яңа көй чыгарганнар дагын шуны биеп күрсәтәләр. Әнә Кәчеләр белән Айбаннар дагын җырлап-уйнап әйләнделәр ич, үнәрләрен күрсәтеп. Кайсы авылныкы

шәбрәк чыга, шунысын отып та калалар... Шуннан бөтен илгә тарала”. [Бәширов, 1990: 68] дип җавап бирә. Бер уйлаганда, бу ике авыл хатынының сөйләшүе кебек кенә тоелса да, шушы әңгәмәдә, халык иҗатының туу һәм таралу мөмкинлекләре, халыкның югары зәвыклы тәнкыйтьче булуы һәм үз күңеленә ошаганын гына отып алулары турында бик әһәмиятле фикер әйтелә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, әдәби әсәр текстында халык авыз иҗаты үрнәкләре, аеруча җырлар һәм бәетләр шактый еш кулланыла. Аларның вазифасы күптөрле. Алар геройларның хис-кичерешләрен тулырак чагылдыру сөйләмне матурлау, эмоциональлекне арттыру өчен хезмәт итәләр. Кайбер очракларда аерым вакыйгалар җыр яки бәет сюжетына нигезләнеп тасвирлана. Әдәби әсәрдән җыр текстларын укып, без шул чорда кайсы төркемгә кергән җырларның популяр булганлыгын да күрә алабыз. Еллар үткән саен, халык җырлары онытыла бара, аларның гамәли әһәмите кими. Һәм киләчәктә әдәби әсәр тексты кайчандыр гамәлдә булган җырларны саклап калуда бердәнбер чыганак булып калырга да мөмкин.

Әдәбият:


1. Бәширов Г. Туган ягым – яшел бишек // Г. Бәширов. И язмыш, язмыш: Повестьлар. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1990. – 477 б.
2. Миңнуллин К. Һәр чорның үз җыры // К.Миңнуллин. – Казан: Мәгариф, 2003.- 400 б.

**Заявка на участие в конференции**

ФИО (полностью) Замалиева Луиза Фирдусовна

Полное наименование организации на русском и английском языках ____________________________

Должность, ученая степень, ученое звание кандидат филологических наук, доцент

Название доклада на русском и английском языках Аннотация доклада на русском и английском языках (не более 10 строк)

Название: Песни и баиты в литературном произведении

Аннотация: Статья посвящается изучению роли народных песен и баитов в тексте литературного произведения. На материале повести Г.Баширова «Родная земля – моя колыбель» исследователь выявляет, что в тексте можно использовать все виды народных песен: обрядовых, исторических, плясовых, и лирических, и все они имеют свои функции. Результаты исследования дают возможность увидеть, какой вид народных песен был популярен среди населения в определенное историческое время.

*Zamalieva Luiza Firdusovna*

*Title*: Songs and baits in a literary work

*Summary*: This article is devoted to the role of folk songs and baits in the text of a literary work. On the material of the story "Native land - my cradle" by G. Bashirov the researcher reveals that in the text it can be used all kinds of folk songs: ritual, history, dance, and lyrical, and they all have their functions. The results of the research provide an opportunity to see what kind of folk song was popular among the people in a certain historical period.

Адрес (с указанием почтового индекса) 420056, Казань, ул. Алданская, 17

Телефон, факс (с указанием кода страны, города) 89872-61-04-54

E-mail zamalluiza@mail.ru

Форма участия в конференции (выступление с докладом / выступление с докладом и публикация / только публикация статьи) выступление с докладом и публикация

Дополнительная информация

Дата ____________ Подпись ________________